
Галиуллина, Миләүшә "Куркак батыр", яки Кинаяле тамаша / М. Галиуллина // Мәдәни җомга. – 2024. – №48 (6 декабрь). – Б. 18.

# «Куркак батыр», яки Кинаяле тамаша

*Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрында «Куркак батыр» исемле бик хикмәтле спектакль сәхнәләштергәннәр. Ә.Фәйзинең «Аучы Мәргән белән Болан кыз әкияте»нә нигезләнеп, инсценировканы шагыйрә Лилия Гыйбадуллаңа язган икән. Спектакльне куйганда исә режиссер Илсур Казакбаев да әсәргә уз өлешен керткән.*






Беренче караганда вакыйгалар бик гади кебек. Үткән гасырның 1990 еллары сурәтләнә. Урам малайлары, тырышып укучы тәртипле балаларны гараж артында сагалап торып, ясак түләтә. Куркытылган корбаннарның исемнәре Гүзәл, Бәхтияр, Илгизәр, Зөбәрҗәт, Мөбарәк. әмма алар үзләренә «тавык», «сасы көзән», «сарык», «бозау», «ишәк» дип дәшүгә риза булып йөри, матур мәгънәле исемнәрен якларлык та хәлләре калмаган. Куркаклар илендә исемнәр юк. Исемсез, хәтерсез ил Куркаклар иле булгач, димәк, үзеннән-үзе, хөр илдә батырларны исемләп беләләр, алар турында хәтерне яңартып торалар, дигән фикер аңлашыла. Ахырдан куркаклар үзләрендә «Ханский»ларга каршы торырлык көч таба һәм Куркаклар иле Йөрәклеләр иленә әйләнә. Баш герой Батырның этисе белән мөнәсәбәте аркылы спектакльгә аталар һәм балалар проблемасы килеп кергән. Әтисе Батырны «йә син, йә сине җиңәләр» дип кырыс итеп үстергән, нәтиҗәдә, баланың йөрәгендә әгисенә карата нәфрәт уты кабынган. Әтисеннән курку хисе үсеп, тормыштан курку булып әверелгән. Бу вакыйгалар әкият белән үрелеп бара, тема кисешкәнгә күрә, бер сәхнәдә борынгы заман һәм үткән гасыр вакыйгаларының бергәлеге бер дә гаҗәп тоелмый.

Әмма ни өчен режиссер вакыйганы 1990 елларга күчергән соң? Геройлар пионер галстуклары бәйләгән. Телевизордан Чечен сугышы, Джохар Дудаев турында сөйлиләр. «В мире животных» телевидение апшыруыннан музыка яңгырый. «Ералаш» альманахын, «Спокойной ночи, малыши» балалар тапшыруын, Совет заманында нәниләр яратып караган «Ну, погоди!», «Мама для мамонтёнка» мультфильмнарын күрсәтеп ник режиссер тамашачыны хыялда гына булса да үткән гасыр ахырына күченергә чакыра? «СССР» язулы олимпийкалар кигән геройлар, гараж ишегендә

«Цой исән» дигән язу, фатир диварында боланнар төшергән ялма нигә кирәк? Кем өчен куелган бу спектакль? Совет заманында яшәгән урта буынгамы, өлкәннәргәме, әллә бүгенге яшьләр өченме? Бүгенге яшь буын өчен сәхнәләштерелгән икән, пионерлар тормышын күрсәтеп түгел, үзләре аңлаган телдә сөйләшү уңышлырак булмас идеме икән? Әмма бу тамашаның бөтен хикмәте дә шунда - ул өлкәннәрне дә, яшь буынны да уйга салырлык. Режиссер, Эзоп теленә күчеп, безгә бик мөһим нәрсәләр турында әйтергә теләгән. Чынлыкта, пионер галстугы, олимпийкалар антураж гына. Сәхнәдә кыйбласын җуйган ил турында сүз бара. Ясак түләү, телевизордан канкоеш турында сөйләүләр - болар барысы да бүгенге көнгә киная. Батыр исемле пионер малайның куркуы - чынлыкта бүгенге җәмгыятьне биләп алган курку хисе ул.




*«Курка-курка ята яга,*
*Курку чире ега тора*
*Аталардан балаларга...*
*Курку хисен онытмагыз*
*Дәваларга, дәваларга...»*

Спектакль геройларының бу җыр сүзләре безне уятыр, аңга китерер өчен җырланмыймыни? Курку иленең иманына әйләнгән заманда яшибез ләбаса. Бүген без барыбыз да куркып яшәргә һәм кара тиргә батканчы эшләп ясак түләргә дучар ителеп, башка бернинди хокукка, бәхеткә ия булмаган коллар түгелмени? Яшүсмерләр тормышыннан беренче мәхәббәт, аталар һәм балалар проблемасы турындагы әсәр әнә нинди борылыш ала.

Әмма режиссер болар белән генә тукталмыйча, дөньяны матурлык түгел, ярату коткарачак дигән фикер дә үткәрә. Канга батканчы сугышу өчен без таш гасыр кешеләре түгел, мәгарәдән чыгарга вакыт, кол булып калтырап җан асрыйсың килмәсә, үз бәхетең өчен көрәш, дип фикерен җөпләп куя.

Менә шундый күп мәгънәле, хикмәтле спектакль килеп чыккан. Режиссерлар арасында, кинаяләп булса да, үз фикерләрен кыю рәвештә җиткерүчеләр булуы сөендерә. Яшүсмерләр дә, аларның әти-әниләре дә бу спектакльдә үзләренә кирәк әйберне табып, уйланып, үзгәреп китәчәгенә һичбер шик юк. Кыюлык вакыт-вакыт чамадан да ашкан. Яшүсмерләрнең үзара сугышу күренешләре артык миһербансыз сәхнәләштерелгән. Балалар һәм яшүсмерләр театрында бу мәсьәләгә бик сак карарга кирәклекне онытмасак иде. Әмма шуңа да карамастан, режиссер, Башкортстан Республикасының Ш.Бабич исемендәге дәүләт яшьләр премиясе иясе Илсур Казакбаевның бу иҗат эше игътибарга һәм кыюлыгы өчен мактауга лаек.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА-